




**Автор: Люция Аблеева**

# Чакмагыш җыры




Гүзəллекнең,
матурлыкның
Ходай биргəне бездə.
Тəгəрəшеп үстек, дуслар,
Чакмагыш төбəгендə.
Эчкəн суыбыз да безнең
Чəрмəсəннең үзеннəн.
Якты кояш нуры китмəс
Якташларым йөзеннəн.
Чакмагышның халкы аның
Горурлыгы Ватанның.
Тарата бөтен дөньяга
Туган җиремнең данын.
Туган ягым, һəрвакытта
Күгең булсын кояшлы.
Суларың көмештəй чиста,
Җирлəрең ундырышлы.

## *Чакмагыш*




Чакмагышның бәрәкәтле
Туфрагында туганбыз.
Без-Чакмагыш балалары
Барыбыз бер туганбыз.
Эх, безнең Чакмагыш
Тирә-якта бер генә.
Тап төшермәс исемеңә
Егет-кызларың бер дә.
Ислəрдəн дә чыкмыйсың
Теллəрдəн дә төшмисең.
Чакмагышым- туган ягым
Куңеллəрдəн китмисең.
Эх, безнең Чакмагыш
Тирә-якта бер генә.
Тап төшермәс исемеңә





## *“Яшьләр урамы”, диләр.*

Нәкъ Тозлыкушка кергәндә,
Бардыр бер урам -
“Яшьләр урамы”, диләр.
Бу урамда яшәгәннәр
Гел уңган-булган, диләр.
Тукаебызга ияреп,
Башлыйм әле сүз башын.
Йөз утыз ел туганына
Быел шагыйребезнең.
Ярый, кайтыйм сүз башына,
Сүз башым бит Тозлыкуш.
“Яшьләр урамы” хакында
Бәян итәргә тиеш.
Бу урамда туганыма,
Горурланам, мактанам.
Мәснәви белән Хәятның
Дүртенче кызы булам.
Без үскәндә биш кенә йорт
Иде безнең урамда.
Хәзер шаккатып торамын,
Ышанмыйм, карыймын да!
Урамыбыз, әйткәнемчә,
Гел мактанып торырлык.
Өч колхоз председателе!
Бу әлбәттә, горурлык.
Мәктәп директорларын да
Бирде урам икене.
Укучылары гел яхшы
Укыдылар, билгеле.
Шуңа алар алдынгыдыр
Һәрберсе хезмәтендә.
Сере – урам оеткысы
Ныклыгы, шәплегендә.
Нурлар балкытып утыра
Һәр йорты-ихатасы.

# *Тозлыкуш җыры*



Бу җирдә ата-бабалар
Туездан корган куыш.
Шуңа микән
авылыбызның
Исемнәре Тозлыкуш.
Аръяк урамы ягында
Балыклы буасы бар.
Һәркем өчен юлы ачык,
Күңеле һич түгел тар.
Әнкәйләрнең бишек
җыры
Тибрәлә һавасында.
Җан азыгыбыз ул
безнең,
Таяну ноктасы да.

Кушымта:
Их, Тозлыкуш, Тозлыкуш
Кушсаң алма, алсаң куш.

Иң гүзәл гөлгә генә тиң
Синдәге хәят-тормыш.

## *Кайтам әле*



Нәсел җебем монда тезелгән,
Газиз әнкәм синдә күмелгән.
Кайтам сиңа, кайтам, Тозлыкуш,
Язын, җәен, көзен һәм дә кыш.
Әткәй көтә мунча уздырып,
Елга балыклары кыздырып.
Сүндермичә тормыш учагын,
Истәлеген бала чагымның.
Тупсабызда – әнкәй эзләре
Бакчабызда – гүзәл гөлләре.
Өй эчендә – әткәй җылысы,
Туган нигез – яшәү ырысы.

## *Туган авылым, Тозлыкуш!*



Барыбызга да бер тигез,
Барыбызга да таныш.
Үзеңә тартып торасың,
Туган авылым, Тозлыкуш!
Сагынып яши, читләрдә
Оя корганнар, китеп.
Юатасың, тирбәтәсең
Һәр балаңны үз итеп.
Кояш җылысы туйдырмый,
Тансыклыйбыз синекен.
Туган авылым, Тозлыкушым,
Йөрәгендә һәркемнең.
Тамырыбыз безнең синдә,
Саклыйк, кадерен белик.
Шушы җирдә орлык чәчеп,
Уңышын җыеп яшик.

# Авылым чишмәсе



Әкрен генә, үзенчә юл алып,
Ага Тозлыкушның чишмәсе.
Нидер сөйли, нидер көйли кебек –
Һәр чишмәнең үзенең гыйлләсе.
Туган якның иң кадерле сые –
Чишмә суы белән эчкән чәй.
Тик шул сыйдан аерылмас өчен,
Чыгып торсын иде һәрчак җай.
Күңелне иркәли, кайтмасаң телгәли
Туган якның чишмә-сулары.
Шат булырлар, алар яши дисә,
Әнкәй-әткәйләрнең рухлары.

# *«Аерма коесы» җыры*



«Аерма» дигән кое бар,
Тозлыкуш авылында.
Суларының тәме һәрчак
Тора тел очларымда.
«Аерма»га барам әле,
Көянтә-чиләк асып.
Җырлап җибәрәсем килә,
Ташкайларына басып.
«Аерма»га ачып салдым,
Эчемдәге серләрне.
Җанкаема җиткерсен дип,
Минем сөюләремне.
«Аерма», «Аерма»
Суларыңнан аерма.
«Аерма», «Аерма»
Авылымнан аерма.

# *“Гөберле кое”*



Урман юлында
“Гөберле кое”.
Тере җаннарга
Шифалы суы.
“Гөберле кое”–
Гомерле кое.
Безнең авылның
Сүрелмәс нуры.
Җиләктән арып,
Сусап кайтканда.
Әнкәй һәрвакыт
Синдә туктаган.
“Гөберле кое”
Хәлләр керткәнсең.
Тик озын гомер
Теләмәгәнсең.
Әнкәй эзләре
Ята ярылып.
Кайда соң үзе?
Елыйм, сарылып.
“Гөберле кое”
И, ярдәм итче!
Минем әнкәйне
Гомерле итче.

**_Тозлыкуш, Сыйрышбаш_**



Ике авылга сарылып
Ага Сарыш елгасы.
Тозлыкуш, Сыйрышбаш
Биш чакырым арасы.
Чиратлашып бер-берсенә
Төшерәләр киленнәр.
Сыйрышбаш, Тозлыкуш,
Бигерәк пар килгәннәр.
Бик билгеле шәхесләрне
Тудырган бу авыллар.
Сыйрышбаш,
Тозлыкушның
Горурлыгы бит алар.
Бер туганның ике улы
Сыйрышбаш,Тозлыкуш,
Икесе дә, күз тимәсен,
Бердәй уңган һәм тырыш.
Ял иткәндә сынатмыйлар
Туктап тыңла узганда.
Сандугачлар тынып кала
Халкы җырлар сузганда.
Ике авылга сарылып
Ага Сарыш елгасы.
Тозлыкуш, Сыйрышбаш
Җаным сездә каласы.